ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

31.07.2024
1121

«Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 31 маендагы 390 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 сентябрендәге 1150 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын расларга (кушымта).
2. Түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:
   2.1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 1356 номерлы карарын;
   2.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2025 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль

программасын раслау турында» Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 1 декабрендәге 1356 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 31 маендагы 119 номерлы карарын.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) әлеге максатларга җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
31.07.2024, 1121
номерлы карарына 1 нче кушымта

# «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы

**Муниципаль**
**программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br><br>Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге |
| Программаның максаты | Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның чагылышларына китерә торган шартларга каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә каршы мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы торучы корал һәм механизмнарны, шул исәптән, хокукый һәм оештыру өкәсендәгеләрне, камилләштерү.<br>2. Норматив хокукый актларда һәм акт проектларында, һәм норматив хокукый акт проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү, коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән норматив хокукый актлар проектларында, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре уздыру юлы белән коррупция халәтендә һәм коррупциягә каршы торуда процессларны һәм тенденцияләрне объектив бәяләүне тәэмин итү.<br>4. Коррупциягә каршы укытуны активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү.<br>5. Муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен үтемле булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, |

| | |
|---|---|
| | җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы көрәш активлыгын стимуллаштыру.<br>6. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү.<br>7. Эшкуарлыкка (бизнес-структурага) административ басымның эзлекле киметү.<br>8. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>9. Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү чараларын көчәйтү. |
| Гамәлгә ашыру вакыты | 2024-2027 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән Программаны финанслау күләмнәре | Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 200,00 мең сум тәшкил итә:<br><br>Ел — Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары<br>2024 — 50,0<br>2025 — 50,0<br>2026 — 50,0<br>2027 — 50,0<br>Барлыгы — 200,00<br><br>Искәрмә: финанслау күләме фараз характерында һәм, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2027 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>- коррупциягә каршы тору процессларында иҗтимагый оешмаларның активлыгын арттыру;<br>- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән өлеше, 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- проектларын эшләү чорында коррупциягә каршы |

Нested table (financing):

| Ел | Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2024 | 50,0 |
| 2025 | 50,0 |
| 2026 | 50,0 |
| 2027 | 50,0 |
| Барлыгы | 200,00 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| | экспертизага дучар ителгән закон һәм башка норматив хокукый актларның өлеше, 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- квалификация күтәрүне узган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләренең өлеше ел саен, кимендә 33 процент тәшкил итәчәк;<br>- коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыруда муниципаль хезмәткәрләрнең өлеше, кимендә 70 процент тәшкил итәчәк;<br>- гражданнарның муниципаль хезмәтләр сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен арттыру, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- «бер тәрәзә» принцибы буенча гражданнарга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү һәм шулай ук хезмәт күрсәтүләрне алганда уңайлы шартлар тудыру өлеше, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларын урнаштыруга һәм аларның бүлекләрен тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карары һәм законнар белән билгеләнгән таләпләр нигезендә, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларындагы бүлекләрне тулыландыру өлеше, кимендә 90 процентка җиткерү;<br>-Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү өлеше, кимендә 100 процент тәшкил итәчәк. |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика Төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Коррупция җәмгыять өчен бик куркыныч социаль күренеш, чөнки ул җәмгыять тормышының барлык тармакларына да: икътисадка, социаль тармакка, сәясәткә таркаткыч дәрәҗәдә йогынты ясый. Шуңа бәйле рәвештә соңгы елларда Россиядә дәүләт дәрәҗәсендә куелган иң мөһим бурычларның берсе-коррупциягә каршы тору.

Коррупция конкурентлыкка сәләтле икътисад формалашуга киртә булып тора, халыкның тормыш-көнкүреш үсешен, алга киткән гражданлык җәмгыяте барлыкка килүне тоткарлый.

Әлеге Программа, беренче чиратта, җирле үзидарә органнарында коррупция тудыра торган шартларны ачыклау һәм бетерү нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән программа чаралары системасын күздә тота, коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру кысаларында коррупциягә каршы көрәшнең бурычларын, төп юнәлешләрен һәм коррупциягә каршы көрәшнең нәтиҗәле системасын булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлеген билгели.

Югарыда күрсәтелгән органнарда һәм җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларның эш сыйфаты яхшыруы һәм активлашулары күзәтелә.

Коррупциягә каршы әүвәлге программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе буларак, коррупциягә каршы эшчәнлектә гражданнар җәмгыяте институтларының роле артуы белән билгеләнә. Шулай итеп, җәмәгатьчелек вәкилләре халык хакимияте органнары каршындагы коррупциягә каршы комиссияләр, дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү буенча комиссияләр, конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелделәр. Яшьләр иҗтимагый оешмалары һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары коррупциягә каршы эшчәнлекнең актив катнашучылары булдылар, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә карата түземсезлек формалаша.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максатлары булып коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның чагылышларына китерә торган шартларга каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә каршы мөнәсәбәт формалаштыру тора.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү таләп ителә:

- коррупциягә каршы торучы корал һәм механизмнарны, шул исәптән, хокукый һәм оештыру өкәсендәгеләрне, камилләштерү;
- норматив хокукый актларда һәм акт проектларында, һәм норматив хокукый акт проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү, коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән норматив хокукый актлар проектларында, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү;
- мониторинг тикшеренүләре уздыру юлы белән коррупция халәтендә һәм коррупциягә каршы торуда процессларны һәм тенденцияләрне объектив бәяләүне тәэмин итү;
- коррупциягә каршы укытуны активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, коррупциягә каршы торуга кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү;
- муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен үтемле

булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы көрәш активлыгын стимуллаштыру;

- дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү;

- эшкуарлыкка (бизнес-структурага) административ басымның эзлекле киметү;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

- көнкүреш коррупциясен минимальләштерү чараларын көчәйтү.

Программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- коррупциягә китерә торган сәбәпләрне бетерү һәм аның чагылышына китерә торган шартларга каршы тору;

- Алабуга муниципаль районында гражданнар җәмгыятен коррупциягә каршы тору сәясәтнен гамәлгә ашыру процессына җәлеп итү;

- җәмгыятьтә коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру;

- коррупция юнәлешендәге җинаятьләрне профилактикалауның әлеге категориядәге җинаятьләрне ачуның иң характерлы мисалларын күрсәтеп, коррупция юнәлешендәге җинаятьләрнең торышын һәм профилактика нәтиҗәләрен мониторинглау.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2024-2027 еллар.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук программада каралган чараларны финанслау күләмнәре программа кушымтасында бирелгән.

## III. Программа чаралары исемлеге

Программа түбәндәге төп эшчәнлек юнәлешләре буенча чараларны үз эченә ала:

Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру механизмын булдыру буенча оештыру чаралары;

Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы сәясәтне норматив хокукый һәм методик яктан тәэмин итү;

Норматив хокукый актларның, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары проектларының коррупциягә каршы экспертизасы;

Коррупциягә каршы факторларны һәм коррупциягә каршы сәясәт чараларын мониторинглауны оештыру;

Җирле үзидарә органнарында кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында коррупциягә каршы механизмнарны гамәлгә кертү;

Җирле үзидарә органнарында эчке контрольне кертү;

Коррупциягә каршы пропаганда һәм агарту оештыру.

Коррупциягә каршы муниципаль программаның бурычлары, чаралары һәм индикаторлары исемлеге 1 номерлы кушымтада китерелгән.

## IV. Программаны ресурслар белән тәмин ителешен дәлилләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 2024 - 2027 елларда Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 200,00 мең сум тәшкил итә.

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. Моннан тыш, программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла.

## V. Программаны гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү механизмы

Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул ел саен программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын төгәлләштерә, Программаның үтәлеше өчен җаваплы кешеләрдән аның үтәлеше турында белешмәләр соратып ала.

Программаны гамәлгә ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеге булган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чараларны финанслау аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы һәм Программаны башкаручы булган җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр аша гамәлгә ашырыла.

Тиешле чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Программаларны үтәүчеләр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына квартал саен хисап чорыннан соң килүче айның 25 числосына кадәр чараларның үтәлеше һәм шул чараларны үткәрүчеләргә бүленеп бирелгән акча чыгымнары хакында үсешле нәтиҗәләргә, һәм, тулаем алганда, хисап елы өчен тотылган акча турында мәгълүматларны тапшыралар.

Программаны гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, хисабыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр башкаручылар белән берлектә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшыра.

Еллык хисапта түбәндәгеләр керә:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;
- билгеләнгән вакытта башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп)

чаралар исемлеге;

- программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

- чаралар башкаруга бюджет ассигнованиеләреннән һәм башка акчалардан файдалану турындагы күрсәткечләр һәм башка мәгълүматләр.

Программага үзгәрешләр кертү Программаның чараларын җаваплы башкаручы белән килештереп йә билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында
коррупция сәясәтен гамәлгә ашыру»
муниципаль программасына 1 нче кушымта

# Муниципаль коррупциягә каршы программаның бурычлары, чаралары һәм индикаторлары исемлеге

| № т/б | Чараның атамасы | Гамәлгә ашыру чоры | Индикаторның исеме | Индикаторның үлчәү берәмлеге | Индикаторның төп әһәмияте | | Еллар буенча индикаторның план күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәткеч | ел | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | |
| 1.1. | Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә федераль, республика законнарын үтәү һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нигезендә үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла) | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары өлеше, алар федераль һәм республика законнарына туры китерелде | процентларда | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. | «Федераль дәүләт хезмәте вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүне тикшерү турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүне тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазифаи затлары) профилактикалау буенча Алабуга муниципаль районы | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителгән оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы көрәш механизмы | процентларда | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | | | | | | | | | |
| 1.3. | Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычын, функцияләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрне бәяләү һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән (кирәк булганда) төгәлләштерүләр үткәрү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 1.4. | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш комиссиясе эшенең еллык планнарын раслау һәм үтәү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 1.5. | Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең шәхси эшләренә анализ ясау һәм мондый хезмәткә кергәндә тапшырыла торган анкеталардагы белешмәләрне, аларның туганнары (абыйларының һәм апаларының хәләл җефетләре, ир туганнарының һәм ир туганнарының сеңелләре турында) һәм үзлекләре турында, мәнфәгатьләрнең мөмкин булган конфликтын ачыклау максатларында актуальләштерү | 2024-2027 еллар | Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең коррупциягә каршы тору өлкәсендәге закон таләпләрен бер елга планлаштырылганнарның гомуми саныннан үтәвен тәэмин итүгә юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның өлеше | процентларда | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |
| 1.6. | Алабуга муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләүләр һәм тыюларның үтәлешенә, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлегендә катнашу предметына, «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» федераль салым хезмәтенең белешмәләр базасыннан файдаланып, башка мәгълүмат системаларыннан (елына кимендә бер мәртәбә) тикшерү үткәрү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 1.7. | Алабуга муниципаль районының муниципаль вазифаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар идарәсендә катнашуларына мониторинг ясау | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 1.8. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар белән эш алып бару, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Федераль законның 13.3 статьясы нигезләмәләрендә каралган чараларны күрү бурычын үтәүне тәэмин итү максатларында коррупцияне кисәтү, шул исәптән оешмалар мәнфәгатьләре конфликтын ачыклау, кисәтү һәм җайга салу буенча чаралар үткәрү | | | | | | | | | |
| 1.9. | Коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләр үтәлмәгән һәр очракта законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 1.10. | Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәте вазифаларын биләүче затлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга, шул исәптән алар үтәлмәгән очракта, мондый затларны җаваплылыкка җәлеп итүгә кагылышлы коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 2. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү, Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү | | | | | | | | | |
| 2.1. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү һәм күрсәтелгән экспертизаны уздыру нәтиҗәләрен гомумиләштерү | 2024-2027 еллар | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән муниципаль норматив хокукый актлары проектларының өлеше | процентларда | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 2.2. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын норматив хокукый актлар проектларын әзерләү турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен төзелгән http://tatarstan.ru/regulation рәсми сайтта урнаштыру | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 3. | Алабуга муниципаль районында коррупция торышын бәяләү | | | | | | | | | |
| 3.1. | Коррупциоген факторларны һәм гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы чараларны максатчан төркемнәр арасында тармак тикшеренүләре уздыру һәм әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен бастырып чыгару | 2024-2027 еллар | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | шартлы берәмлекләр | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | | | | | |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы тору өчен гражданлык җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү | | | | | | | | | |
| 4.1. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аның карамагындагы оешмаларда коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру эшен гамәлгә ашыру, шул исәптән коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы чаралар уздырылган Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең өлеше | процентларда | 50 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.2. | Район иҗтимагый советы утырышларында коррупциягә каршы тору программаларын гамәлгә ашыру турында хисапларны карау | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 4.3. | Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен квалификация күтәрү программалары буенча укытуны | 2024-2027 еллар | Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертелгән программалар буенча | процентларда | 33 | 2023 | 33 | 33 | 33 | 33 |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру, белем бирү программаларына коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертү | | квалификация күтәрүче Алабуга муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләр өлеше | | | | | | | |
| 5. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачык булуын, гражданнарның файдалана алуын тәэмин итү, граждан җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | | | |
| 5.1. | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарында ышаныч телефоннары, кайнар линияләр, интернет-кабул итү каналлары, аларга мәгълүм коррупция фактлары, аларны башкаруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүмат каналлары эшчәнлеген тәэмин итү | 2024-2027 еллар | Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, гражданнарның файдалана алуын тәэмин итүгә, гражданнар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлеккә, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга, бер елга планлаштырылган гомуми саныннан уздырылган чаралар өлеше | процентларда | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 33 |
| 5.2. | Массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затлар мөрәҗәгатьләрендә булган Алабуга муниципаль районы вазифаи затлары эшчәнлегендә коррупциягә каршы тору комиссияләре утырышларында квартал саен гомумиләштерелгән һәм аның нәтиҗәләрен коррупциягә каршы көрәш комиссияләре утырышларында, районның коррупциягә каршы көрәш эшен | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | координацияләү комиссиясендә карау турында мәгълүмат мониторингы үткәрү | | | | | | | | | |
| 5.3. | Алабуга муниципаль районы рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенең мәгълүмат стендларын рәсмиләштерү һәм актуальләштерү һәм коррупциягә каршы эчтәлекле мәгълүмат бирүнең башка формалары | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 5.4. | Тормыш эшчәнлегенең социаль-икътисадыиармакларында коррупция күренешләре турында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг үткәрү | 2024-2027 еллар | | | | | | | | |
| 6. | Алабуга муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | | | | | | |
| 6.1. | Муниципаль ихтыяҗлар товарларын (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган сатып алуларның ачыклыгын һәм алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү чараларын үткәрү, шулай ук сатып алуларда | 2024-2027 еллар | Тикшерү барышында контроль органнары тарафыннан Алабуга муниципаль районы вазифаи затын сатып алу объектын тасвирлау кагыйдәләрен һәм контрактның башлангыч максималь бәясен формалаштыру кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту турында чыгарылган | шартлы берәмлекләр | 0 | 2023 | 30 | 30 | 30 | 30 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру | | карарлар, сатып алулар өлеше. * | | | | | | | |

*Күрсәткечнең әһәмияте≤ 30 билгесе белән.

Документ создан в электронной форме. № 1121 от 31.07.2024. Исполнитель: Мусина Е.А.
Страница 20 из 21. Страница создана: 02.08.2024 14:43